КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 август

г.Казань

№ 727

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2019 ел, 16 декабрь, 1144 нче карары белән расланган Урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2019 ел, 16 декабрь, 1144 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 февраль, 118 нче, 2020 ел, 15 май, 393 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү яшь белгечләргә беренче өч ел дәвамында түбәндәге шартларны үтәп, учреждениедә өзлексез эшләгәндә Министрлык тарафыннан бер тапкыр бирелә:»;

2.1.2 пунктка «салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар,

штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавы турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Күрсәтелгән вакытка түбәндәге чорлар кертелми:

хәрби чакырылыш буенча хәрби хезмәт яки аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтен үтү;

йөклелек һәм бала табу буенча ял, бала карау буенча ял;

аспирантурада көндезге формада уку.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган шартларны үтәмәү һәм әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында каралган документларны тапшырмау, әлеге Тәртипнең 3.1.5 пунктында каралган документлардан тыш, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

3.1 пунктта:

3.1.3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хәрби исәпкә алынырга тиеш граждан турында мәгълүматлар.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.1.5 пункт өстәргә:

«3.1.5. Яшь белгеч бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында гариза бирелгән көнгә кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавы турында белешмә тапшыра (яшь белгеч тарафыннан мондый документ тапшырылмаган очракта, Министрлык аны салым органыннан мөстәкыйль рәвештә соратып ала).»;

5.5 пунктта «4 һәм 8» сүзләрен «1, 4, 8» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин